**СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Мульма, ул. Центральная, 46а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МҮЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Мүлмә авылы, Үзәк ур., 46а

тел./факс 8(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**12 май 2022 ел** **№ 45**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш буенча «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсенең 10.1 нче өлеше нигезендә, коррупциягә каршы көрәш турында федераль законнар таләпләрен бозган өчен, ә атап әйткәндә, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне тапшырмаган өчен, Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Коррупциягә каршы көрәш турындагы законнар белән аңа йөкләнгән бурычларның үтәлмәве сәбәпле, дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге Советы депутаты 8 нче сайлау округы буенча Абдуллин Рәфыйк Рәис улы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы: Л.Р. Зиннатуллин